Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге
Тукай торак пунктында гражданнар җыены
КАРАРЫ

«16» ноябрь 2022 ел № 8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге Тукай торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

Яңа Иглай авыл җирлеге Тукай торак пункты территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан кала 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Тукай авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту.
- Тукай бистәсендә урам утларын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу.
- Тукай бистәсен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу.
- суүткәргеч төзелеше, Тукай п. эчәргә яраклы су белән тәэмин итү

Халык җыенында рәислек итүче: Р.Р. Рәхмәтуллин

Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Рәхмәтуллин